# Сабитова

## Вазиха Муллахметовна

Дата рождения

__.__.1913

Место рождения

Татарская АССР, Елабужский р-н, д. Бизяки

Наименование награды

Орден Отечественной войны II степени

Архив

ЦАМО

Картотека

Юбилейная картотека награждений

Расположение документа

шкаф 52, ящик 21

Номер документа

195

Дата документа

23.12.1985

Автор документа

Министр обороны СССР

Вазиха 1923 нче елда туа. Әтисе – Фатхуллин Муллахмәт, әнисе – Фатхуллина Зифа. Вазиха яшьли, 15-16 яшьләр тирәсендә, Камчаткага китә. Шулай итеп Ерак Көнчыгышта Япония белән сугышка эләгә. Сугыш тәмамлангач Березняки шәһәренә кайта, тормышка чыга. Ире белән 2 бала – 1 кыз һәм 1 ул тәрбияләп үстерәләр. Соңрак кызын Березнякида калдырып , улы Рәфис белән әти-әнисе янына авылга кайта, аларның ризалыгы белән хатыны үлгән Сабитов Хәмәткә тормышка чыга. Хәмәтнең Зөфәр, Гөлнара, Рәвил исемле балалары була. Хәмәт Сабитов Рәфисне усыновить итә һәм үз фамилиясен бирә. Барысы бергә бик тату яшиләр.

Еллар уза, Зөфәр белән Рафис урта мәктәпне тәмамлап , Казанга укырга китәләр. Укып бетергәч Зөфәр Чаллыга, Рафис Алабуга шәһәренә стоматолог булып эшкә урнаша. Еллар үткәч, Вазиха улы Рафис янына Алабуга шәһәренә күчеп китә. Хәмәт абый авылда яшәп кала. Бүгенге көндә Вазиха апа исән-сау, улы һәм килене тәрбиясендә яши. Хәзер ул 93 яшьтә. (Из воспоминаний Шаргии апа Ибатуллиной)